Татарстан Республикасы
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы

# Б О Е Р Ы К

2014 елның 12 марты Казан ш. № 54/2-пр

2014 елда сатылган товар сөтнең 1 литрына (килограммына) авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр чыгымнарын каплауга субсидияләр бирү өчен ставкаларны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2014 елда агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында” 2014 елның 21 февралендәге 104 номерлы карарын үтәү максатында

б о е р ы к б и р ә м:

1. 2014 елның гыйнвар-февраль айларында күләмнәре буенча май кимендә 3,4 проџент һәм аксым 3,0 процент булган сатылган товар сотнең 1 литрына (килограммына) ставканы түбәндәгечә расларга, аның буенча акча Татарстан Республикасы бюджетының “1 литры (килограмм) сатылган товар соткә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең чыгымнарының бер олешен каплауга субсидияләр” статьясы буенча бирелә:

а) югары сортлы – 3,89 сум,

б) беренче сортлы – 2,09 сум.

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының (алга таба – Министрлык) азык-төлек базарын үстерү бүлеге башлыгы Е.А. Рещиковка:

2.1. Министрлыкның азык-төлек базарын үстерү бүлеге белгечләре тарафыннан документларның кабул ителүен тәэмин итәргә;

2.2. Татарстан Республикасы муниџипаль районнарында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренең (алга таба – Идарәләр) җыелма реестрлары нигезендә “2014 елда Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан килә торган акчалар исәбеннән субсидиеләр бирү өчен документларның формалары исемлеген раслау турында” 2014 елның 24 февралендәге 34/2-пр номерлы Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча (66 нчы кушымта) җыелма реестр төзергә, аны хисап аеннан соң килә торган айның 10 числосына кадәр Министрлыкның терлекчелек тармакларын үстерү бүлегенә тапшырырга.

3. Министрлыкның терлекчелек тармакларын үстерү бүлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы С.М. Нигъмәтҗановка Министрлык бүлеге белгечләре тарафыннан “2014 елда Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан килә торган акчалар исәбеннән субсидиеләр бирү өчен документларның формалары исемлеген раслау турында” 2014 елның 24 февралендәге 34/2-пр номерлы Министрлык боерыгы белән (2014 елның 12 мартындагы 53/2-пр номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алган) расланган формалар нигезендә документларның кабул ителүен тәэмин итәргә.

4. Министрлыкның финанслау бүлеге башлыгы М.А.Мәхмүтовка Министрлыкның Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында ачылган лиңевой счетыннан акчаларның Идарәләрнең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментының территориаль бүлекләрендә ачылган лиңевой счетларына үз вакытында күчерелүен тәэмин итәргә.

5. Министрлыкка тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2014 елда агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында” 2014 елның 21 февралендәге 104 номерлы карары белән расланган 2014 елда сатылган товар сөтнең 1 литрына (килограммына) авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр чыгымнарын каплауга субсидияләр бирү тәртибендә билгеләнгән шартларның үтәлүе өчен җаваплылык Татарстан Республикасы муниципаль районнарында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгына йөкләнә.

6. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары Н.Л.Титовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов